| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**21.03.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 460** |

Зеленодольск муниципаль район Советының 2013 елның 14 нче ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган (Зеленодольск муниципаль район Советының 2018 елның 29 нчы октябрендәге 329 номерлы, 2019 елның 29 нчы октябрендәге 433 номерлы, 2021 елның 24 нче мартындагы 51 номерлы, 2023 елның 30 мартындагы 256 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль район Советының 2013 елның 14 нче ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган ( Зеленодольск муниципаль район Советының 2018 елның 29 нчы октябрендәге 329 номерлы, 2019 елның 29 нчы октябрендәге 433 номерлы, 2021 елның 24 нче мартындагы 51 номерлы, 2023 елның 30 мартындагы 256 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтева мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә,Зеленодольск муниципаль районы **Советы карар** кылды:

1.Зеленодольск муниципаль район Советының 2013 елның 14 нче ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган ( Зеленодольск муниципаль район Советының 2018 елның 29 нчы октябрендәге 329 номерлы, 2019 елның 29 нчы октябрендәге 433 номерлы, 2021 елның 24 нче мартындагы 51 номерлы, 2023 елның 30 мартындагы 256 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1.29 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «муниципаль хокукый акт белән район Башкарма комитеты тарафыннан расланган программа нигезендә» сүзләрен «район Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «билгеләнгән срокларда» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче абзацта «үз көченә кергән көннән алып өч ай» сүзләрен «агымдагы финанс елның 1 апрелендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 30 статьяның 2 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче һәм алтынчы абзацлар белән тулыландырырга:

«җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау исәбенә җирле бюджетларның керемнәре;

авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлардан җирле бюджет керемнәре».;»;

бишенче - сигезенче абзацларны туры китереп җиденче - тугызынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы , Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**